КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 март г.Казань № 177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче; 2013 ел, 14 февраль, 103 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы; 2014 ел, 9 июль, 479 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы; 2017 ел, 1 ноябрь, 830 нчы; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2019 ел, 23 июль, 618 нче; 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесен» сүзләрен «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы нигезләмәдә:

3 пунктның «д» пунктчасындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 60 көн эчендә «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләр үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе уставларына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин